**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 4 октябрендәге 4188 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2022 елның 1 апрелендәге 916 номерлы**
**«Казан шәһәре территориясендә реклама конструкцияләрен**
**урнаштыру турында»гы карарына**
**үзгәрешләр кертү хакында**

2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы «Реклама турында»гы федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Казан шәһәрендә тышкы реклама өлкәсендә бердәм сәясәтне гамәлгә ашыру максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 1 апрелендәге 916 номерлы «Казан шәһәре территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 17 ноябрендәге 4009 номерлы, 2023 елның 20 апрелендәге 1143 номерлы, 2023 елның 17 июлендәге 1997 номерлы, 2023 елның 28 сентябрендәге 2864 номерлы, 2023 елның 10 ноябрендәге 3430 номерлы, 2024 елның 3 апрелендәге 1275 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 номерлы кушымтада:

1.1.1. 3.2.2 пунктчаның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

«- дини билгеләнештәге объектлар биләп торган территорияләрдә һәм мондый объектлар биләп торган җир кишәрлекләре чикләреннән 100,0 метрдан кимрәк ераклыкта»;

1.1.2. 3.3.1 пунктчаның дүртенче абзацында «дини билгеләнештәге объектлар территорияләре» сүзләрен «мондый объектлар биләп торган җир кишәрлекләре» сүзләре белән алмаштырырга;

1.1.3. 3.3.3 пунктчаның алтынчы абзацын төшереп калдырырга;

1.1.4. III «Казан шәһәре территориясендә төзелгән биналарның архитектура ягыннан тышкы күренешләрен саклау кирәклеген исәпкә алып, Казан шәһәрендә урнаштырырга рөхсәт ителә торган реклама конструкцияләренә карата таләпләр» бүлеген түбәндәге эчтәлектәге 3.4 пункт белән тулыландырырга:

«3.4. Реклама конструкцияләрен аларның тышкы күренешенә һәм техник характеристикаларына карата Казан шәһәре территориясендә урнаштырырга рөхсәт ителә торган реклама конструкцияләре җыентыгы белән билгеләнгән таләпләрне бозып урнаштыру һәм эксплуатацияләү рөхсәт ителми»;

1.2. 3 номерлы кушымтада:

1.2.1. 11 биттәге РП-187 номерлы ноктаны (урынны), 36 биттәге РП-148 номерлы ноктаны (урынны), 43 биттәге РП-154, РП-155 номерлы нокталарны (урыннарны), 120 биттәге РП-19 номерлы ноктаны (урынны), 121 биттәге РП-20, РП-22 номерлы нокталарны (урыннарны), 134 биттәге РП-198 номерлы ноктаны (урынны), 135 биттәге РП-186 номерлы ноктаны (урынны), 139 биттәге РП-174 номерлы ноктаны (урынны), 151 биттәге РП-63 номерлы ноктаны (урынны), 152 биттәге РП-62 номерлы ноктаны (урынны), 154 биттәге РП-56 номерлы ноктаны (урынны) төшереп калдырырга;

1.2.2. 98 биттәге СБ-3 номерлы ноктаны (урынны) әлеге карарга кушымта нигезендә СБ-3 номерлы нокта (урын) дип санарга;


1.2.3. Казан шәһәре территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру схемасына 13 номерлы кушымтадагы таблицада 19, 20, 22, 56, 62, 63, 148, 154, 155, 174, 186, 187, 198 юлларны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 4 октябрендәге
4188 номерлы карарына
кушымта




**ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР:**

**I. Аерым торучы реклама конструкцияләре**

- СС - суперсайт
- СБ - суперборд
- ББ - еврощит
- СР - ситиборд
- ПР - пилларс
- ПЛ - пилон
- ПЛО - җәмәгать транспортын көтү павильоны составындагы пилон
- АФЩ - щитлы афиша конструкциясе
- АФТ - афиша тумбасы
- КУ - коммуникация күрсәткече
- ЭКУ - электрон-цифрлы коммуникация күрсәткече
- РН - тукталыш пунктының җәмәгать транспортын көтү урынында түбәле реклама конструкциясе

**II. Биналарда, корылмаларда урнаштырыла торган реклама конструкцияләре**

- МФ - медиафасад
- РП - тукталыш пунктының җәмәгать транспортын көтү урынында түбәле муниципаль тукталыш корылмасындагы реклама панеле